**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УСЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423739, Качкын авылы,
Үзәк ур., 37в нчы йорт. Тел.3-44-63

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423739, деревня Качкиново,
ул. Центральная,дом 37в,
Тел. 3-44-63

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«16» ноябрь 2019 ел** **№ 29**

**Усы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 16.11.2019елгы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә Усы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. Усы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 1 төркем инвалидлардан кала, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан кала, 2020 елда үзара салымның бер тапкыр 500(Биш йөз) сум түләвен кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- күмү урыннарын карап тоту:
*Усы һәм Качкын авылы зират коймасын ремонтлау;
- автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
*юлларны ремонтлау һәм карау (ком түшәү, урам юлларын грейдерлау, кардан чистарту);
-авыл җирлеге чикләрендә халыкны су һәм электр белән тәэмин итүне оештыру:
*урам утларын карап тоту;
*су үткәрү системасын ремонтлау, карау,су чыганакларын лицензияләү һәм ремонтлау;
- халык күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру.

2. Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Усы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы З.З.Ахмаев